СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шәланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

03.10.2019 с.Соболевское № 76-313

**Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Советының «Соболевский авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында»24.09.2019 ел, № 75-308 карарын юкка чыгару турында**

Соболевский авыл җирлегендә яшәүчеләрнең 03.10.2019 ел мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 26 статьясына, Соболевский авыл җирлеге Уставының 15 статьясына таянып,

**Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:**

1. Соболевский авыл җирлеге Советының «Соболевский авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында» 24.09.2019 ел, № 75-308 карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Соболевский авыл җирлеге Башлыгына гражданнардан үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү инициативасын тәкъдим итергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлеге
Башлыгы О.Н.Майорова**